# КАРАР

## Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Звезда авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Коршанга-Шигали авылында гражданнар җыены

**21 нче ноябрь 2024 ел Коршанга-Шигали авылы №1**

### Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының “Звезда авыл җирлеге " муниципаль берәмлегенең Коршанга-Шигали торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2024 елның 21 ноябре

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлеге Советының 11.10.2019 ел, № 53/1 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда, гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә, 2024 елның 21 ноябрендә төзелгән Хисап комиссиясенең, 2024 елның 21 ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә, тавыш бирү тәмамланган вакытта, җыенда катнашучы 84 кеше кертелгән, гражданнар җыенында катнашучыларның тавыш бирүдә катнашкан саны-**48**, бу исемлеккә кертелгән гражданнарның **57,14** % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан **48** кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде, бу гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучыларның **100%** ын тәшкил итә; «Каршы» позициясе өчен, җыенда катнашучы **0** кеше тавыш бирде, бу **0%** тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә карар иттеләр:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Звезда авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Коршанга-Шигали торак пунктында гражданнар җыенын 2024 елның 21 ноябрендә узган дип таныырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре гамәлдә дип таныырга.
2. 2025 елда Коршанга-Шигали торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлеге башкарма комитеты һәм алган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау" дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. 2024 елда Чүпрәле муниципаль районының Коршанга-Шигали авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау.

4. Үзара салым акчаларын түләүдән азат итәргә:

1) 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнар;

2) инвалид балаларның (уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр) ата-аналарын, тулы дәүләт тәэмин ителешендә булган балаларны исәпкә алмаганда;

3) махсус хәрби операциядә катнашучыларны;

4) махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларын (хатыны (ире), балигъ булган балалар, ата-аналар һәм эшкә сәләтсез башка затлар белән бергә яшәүчеләр), шул исәптән махсус хәрби операция барышында хәбәрсез югалган һәлак булганнар да;

5) Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указына ярашлы рәвештә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар;

6) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренәхәрби хезмәткә мобилизация буенча чакырылган гражданнар гаиләләренең әгъзаларын (хатыны (ире), балигъ булган балалар, ата-аналар һәм эшкә сәләтсез башка затлар белән бергә яшәүчеләр).

5. Әлеге карарны Коршанга-Шигали авылы, Комсомольская урамы, 12 нче йорт, ФАП бинасы адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга

Звезда авыл җирлеге башлыгы,
рәислек итүче граждannар җыенында: М.В.Денисова